# ОПЕРАТОР ХӘМӘТВӘЛИЕВ



Рәфикъ торба очына насосны көйләп бетерүгә Талип, ярдәмчесе күтәрткеч машинисты Җәүдәт ягына борылды. «Тарттыр, әйдә»,—димәкче иде, Рәфикъ кулың аска таба селтәде: туктап тор, янәсе. Машинист хезмәттәшләрен өйрәнеп бетергән инде, бүленеп калды.

Бәширов операторга сораулы караш ташлады.

—Нәрсә бар?

—Берни юк,—диде Хәмәтвәлиев ярдәмчесенә тыныч кына. —Просто, насосны кабат тикшереп аласы.

Талип тирән бер тын алды да, тынычланып чираттагы торбаны әзерли башлады. Оператор үзе торба очына беркетелгән насосны янә күздән кичерде һәм кран кабинада утырган Гыймалетдиновка кул изәде. Җәүдәт шуны тына көтә иде, торбаны күтәртә башлады.

Менә беренче торба скважинага төшеп китте. Рәфикъ һәм Талип ул арада җәһәт-җәһәт яңаларын әзерләргә керештеләр.

Хәмәтвәлиев бригадасы, гадәттә, җир асты скважиналарын ремонтлау белән шөгыльләнә. Әмма кирәк чакта яңа скважиналарны да коралар. Норлат ягындагы нефть аскы катламда, бер километрдан да тирәндә ята. Моның өчен скважинага 8—9 метр озынлыктагы 110—120 торба төшерергә туры килә. Аларны берәмләп төшерелгәннәренә ялгый баралар. Норма буенча һәммәсенә санаулы минутлар бирелгән, шуңа андый көннәрдә операторга һәм аның ярдәмчеләренә дә киеренке эшләргә туры килә. Аны тәмамлауга шул ук тәртиптә штанга төшерә башлыйлар. Алары да 8 әр метрлы өлешләрдән тора.

Скважинага аларны төшереп бетергәч, иң өскә качалка (нефть суырткыч) урнаштырыла. Ул эшләгәндә насос клапаны ачыла һәм нефтьне өскә суырта. Бу, гади әйткәндә, пешкәк белән эшләүче колонкадан су агызу принцибына охшаш. Һәм без качалка эшләп торса нефть килә, эшләмәсә туктаган исәплибез.

—Алай ук түгел шул, —ди Рәфикъ Вәлимөхәммәтович елмая төшеп.—Качалка хәрәкәттә түгел икән, димәк, моторы сафтан чыккан, аны электриклар төзәтә. Ә безнең хезмәт башка. Качалка эшли, әмма нефть килми. Шул чакта безне чакыралар.

Скважина нефть бирмәвенең сәбәпләре төрле. Насос тыгылган икән, 100дән артык торбаны яңадан суыртып алырга, ремонтларга һәм кире салырга туры килә. Алдан күренгәнчә, мәшәкатьле эш. Штанга өзелсә, махсус тоткыч кулланалар, өзек өлешен алмаштыралар. Торбада тишек, ярык булса да катлаулы, һәр торбаны 25 атмосфера басым астында тикшереп чыгарга, йөз арасыннан берне эзләп табарга туры килә.

Һәм табалар, төзәтәләр. Югары квалификацияле оператор Хәмәтвәлиев дефектны тиз табарга өйрәнгән инде. Хәер, унбиш еллап шул хезмәттә эшләгән оста, иң югары, 6 нчы разрядлы белгеч хезмәтендә күпне күргән, башыннан кичергән хезмәт кешесе. Аның кулы белән шул вакытта меңнәрчә скважина яңадан тәртипкә килгән, ил табынына күпме өстәмә «кара алтын» чыгарган.

Ә нефтьче булып китүе очраклы аның. Мәктәптән соң, армиядән кайткач та авылда калырга, икмәк игәргә ниятләгән була ул. Яшьтән таныш, күңелгә якын хезмәткә кулы ятып тора аның. Авылда кемнең кемлеген яхшы беләләр, эшчән егетне солдат шинелен салуга Ульянов исемендәге колхозга бригадир ярдәмчесе итеп куялар. Сукса тимер өзә, центнерны күтәрә, үзе эшләп көн күрергә ярата торган Рәфикъ тәүге хезмәт көннәреннән үк үзен табадагы балыктай хис итә. Аннан иң беренче— күндәмлек: үзеннән югары торганнарны тыңларга, түбәннәргә боера белергә кирәк икән. Үзе белеп эшләргә күнеккән Рәфикъның бу вазифадан шуңа күрә тиз сөмсере коела. Егет эшеме бу?! Машинага күчеп утыра. Тик, озакка түгел—китә. Йортта алар алты малай, дүртенчесе ул: бер өйдә тәялеп ята алмыйлар бит инде. Күптән яратып йөргән Алсуны килеп тәшергәч, башка чыгу мәсьәләсе алга килеп баса. Колхозда ул чакта бүгенге кебек яшьләргә фатир салып чыгару телгә дә кермәгән замана: үз көнеңне үзең күр.

Дөрес, китә башлагач (эшчән ир-ат кайда да кирәк) шул чактагы рәис документларын бирми тарткалашса да, күңеле бер урыннан купкан гаиләне тотып тора алмый.

Лениногорск шәһәрендәге туганнары чакыруы буенча анда барып урнашалар. Скважиналарга җир асты ремонты үткәрүче һөнәрен шунда үзләштерә.Әмма торак мәсьәләсе һич алга атламый. Туган-тумача каршында күпме яшәргә мөмкин соң? Ике ел узгач, 1978 елның җәендә туган якка якын Норлатка күчеп кайталар, буш йортка урнашалар. Ул чакта «Норлатнефть» НГДУсы «Ямашнефть» составында булса да, Андреевкада нефть һәм газ чыгару цехы ачылган була инде. Тагын ел ярым үткәч Норлатта мөстәкыйль нефть һәм газ чыгару идарәсе төзелә...

Идарә белән бергә үсә Хәмәтвәлиев, осталыгын арттыра, квалификациясе дә күтәрелә. Хезмәте белән ихтирам казана. Иң катлаулы скважиналарны сафка бастыруны аңа йөкләтәләр. Аның җитәкчелегендәге бригада аны уңышлы башкара, айлык, еллык планнарын даими арттырып үтәп килә.

Хәмәтвәлиев эшләгән Андреевка цехы Октябрь, Аксубай районнарындагы скважиналарга хезмәт күрсәтә. Цех ай саен планнарын арттырып үтәп килә. Коллективның бу уңышларына III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалеры, «Нефть промышленносте отличнигы» Рәфикъ Вәлимөхәммәтович Хәмәтвәлиевның да хезмәт өлеше керә.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

**Рәсемдә: «Норлатнефть» НГДУсының скважиналарга җир асты ремонты операторы Р. В. Хәмәтвәлиев.**

**Н. Квашнина фотосы.**

---

***Тумбадан язалар***

## Урман эше уңганнары

Николай Тимофеевич Михалкин бригадасының эшләгәнен күзәтергә туры килгәне бар. Бригадир үзе буй агачлар ега. Моторлы пычкысы урманны яңгыратып агач кәүсәсенә керә. Һәм гөрселдәп чираттагы агач ава. Ул арада Михалкин яңа агач янында була инде.

Юлдашлары да үзе шикелле уңганнар. Ботакларны чабучы Валерий Николаевич Осипов та җитез эшли, балтасы тиешле урыннан чаба. Владимир Серафимович Школьников исә ул агачларны трактор белән билгеләнгән урынга чыгара бара.

Һәммәсе өлгер, хезмәтен белеп һәм оста башкара. Шуңа күрә Тумба урманы пункты эшчеләре арасында хөрмәтлеләр дә алар.

Хәер, пунктта үз вазифаларын күңел биреп, авыр урманчы хезмәтен тырышып башкаручы осталар байтак. Буй агачларны кисүдә Владимир Владимирович Киселев бригадасы членнары да уңганлык күрсәтә, үзләренә йөкләтелгән эшне тоткарлыксыз башкара. Иван Павлович Спиридонов агачны штабельләргә өюдә алмаштыргысыз кеше.

Агач эшкәртү цехы работниклары да сынатмыйлар. Пилорамачы Владимир Алексеевич Вяшин хезмәтен тәм табып башкара. Станокчылар Зиннәт Заһидуллович Латыйпов, Асиябану Насыйбулловна Фәссәхова чимал хәзерләү буенча һәр заказны төгәл үтәп киләләр.

**В. АФАНАСЬЕВА,**
Тумба урман пункты бухгалтеры.

## Гаиләләр ишәя

**Педагог Ирина Николаевна һәм урманчылык** техникгы Анатолий Николаевич Семеновлар гаиләсе бу көннәрдә зур шатлык кичерә. Ничек шатланмыйсың ди инде, гаилә тагын бер кешегә ишәйде, өченче балалары —Андрюша туды.

Безнең өчен гаиләдә яңа бала туу—сөенечле күренеш. Шулай булуына гаҗәпләнер урын да юк, авылда яңа бәби бик сирәк күренеш. Быел, мәсәлән, дүрт бала дөньяга килде. Алда телгә алган Андрюша белән бер вакытта диярлек Надежда Петровна Никитина һәм Николай Дмитриевич Буянцов гаиләсендә дә икенче бала—Любовь туды.

Чулпан участок больницасының Тумба филиалы шәфкать туташлары нәниләрнең үсешен даими күзәтеп, тикшереп торалар. Андрюша һәм Люба да сау-сәламәт үсәләр.

**В. МАЙОРОВА,**
**Чулпан участок шифаханәсенең Тумба бүлеге мөдире.**

---

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

**Безнең хуҗасызлык шартларында ничек кыш чыгасы дип кайгырып торасы юк.** Үзебез көтмәгән әллә нинди резервларыбыз барлыгы ачыклана. КПСС байлыгын эзләү белән шөгыльләнгән 50 тикшерүчедән торган группа партиянең төрле банкларга, уртак предприятиеләргә һәм акционерлык җәмгыятьләренә салып куйган 5 миллиард сумнан артыграк акчасын тапты. Моннан тыш төрле җирдән 14 миллион доллар саф акча да кулга төшерелде.

---

## Святскиның соңгы көннәре



Святск авылы Брянск җирендә өч гасыр торды... Һәм хәзер һәлак булды. Аны Чернобыльның күренмәс һәм һәр җиргә үтеп кергән нурлары һәлак итте. Святскины шушы авыл исемен йөртүче изге чишмә суы да коткарып кала алмады. Радиация фоны һәр квадрат километрга 40 кюрига кадәр тәшкил итә, шуңа күрә биредә нык куркыныч.

Кайчандыр бик бай булган XXII партсъезд исемендәге колхоз да юк инде хәзер. Техника һәм терлек сатып бетерелгән. Яшьләр һәм эшләргә сәләтле барлык кешеләр күптән инде «чиста» якларга киткәннәр. Ә шушы зарарланган утраучыкта беркая да китә алмаслык 170 карт кеше генә калган...

Новозыково автостанциясе диспетчеры авылга автобус бирүдән баш тарта. «Сезне бетерделәр бит»,—ди ул. Биредә яшәүчеләр кичләрен урамга чыгарга мародерлардан куркалар. Узган ел гына да авыл чиркәвенә 15 тапкыр кергәннәр. Анда XVIII—XIX гасырлардагы дистәләрчә икона югалган. Святскида Совет власте әлегә элек авыл Советында бухгалтер булып эшләүче Мария Григорьевна Усова кулында. Хәзер аның бурычы бер: картларны «чиста» районга урнаштыру. Күп кенә урыннарда аларны кабул итүдән баш тарталар, фәкать эшче көчләр кирәк.

Новозыбковода аларга коммуналь квартиралар тәкъдим итәләр, ә үз йортлары һәм хуҗалыклары белән яшәүчеләрнең анда барасылары килми.



**Рәсемнәрдә: Чернобыль фаҗигасеннән соң шушы гаҗәеп сарайны төзү өчен җирле властьлар миллион сум сарыф иттеләр, ә хәзер ул беркемгә дә кирәкми.**

«Кайда гына барсаң да кочак җәеп каршылаучы юк»,—ди Вера Прохоровна Усова.

Л. Свердлов фотолары.

ТАСС фотохроникасы.

# БЕЗНЕҢ ГОРНЯКЛАР

Тарн-Вар бентонит һәм керамзит балчыгы ятмасы 1961 елда ук ачылган иде, ә «Нефтегазразведка»ның Казан геологик экспедициясе тарафыннан ул 1964—1966 елларда гына тикшерелеп бетте. Ятманы эшкәртү 1963 елда башланды. Аның Норлат шәһәре янында, тимер юлдан ерак түгел җирдә булуы транспорт өчен яхшы шартлар тудыра.

Карьер элекке елларда бентонит балчыгы гына бирде, ә өске катламдагы керамзит балчыгы алып кына ташланды.

1982 елда, карьер Казан керамзит заводы буйсынуына күчкәч, ятманың өске катламы тикшерелде һәм заводны керамзит балчыгы белән тәэмин итә башлады. Продукция төзелеш өчен алыштыргысыз чимал икән.

Хәзерге вакытта карьер 380—400 метр озынлыгындагы турыпочмакны хәтерләтә. Биредә эш карьер эшкәртү проектына туры китереп җирне йомшартып алып барыла. Аны 1981 елда Тула конструктор-техник институты эшләгән.

Алынган балчык рельс буе складларына үзбушаткыч машиналарда китерелә һәм тимер юл буендагы складларга 8 метр биеклектә итеп өелә. Балчык Казан заводына тимер юл белән озатыла.

Карьерда эшләр бер сменада ел әйләнәсе диярлек алып барыла. Тик җир суга туйган апрель, октябрь айларында гына эш тоткарлана.

Карьерның хезмәт җитештерүчәнлеге заводның чималга булган ихтыяҗына, керамзит гравие җитештерү планына һәм кирәкле запас булдыруга бәйле. Мәсәлән, былтыр карьердан 100 мең кубметр балчык алынган. Быел да эшләре көйле бара коллективның.

Биредә тәҗрибәле, оста оештыручы В. Н. Кутузов җитәкчелегендәге тату, бердәм коллектив эшли.

Билгеле инде, коллективның горурлыгы кешеләр. Алар— экскаватор машинистлары М. Ш. Сатдаров, И. Д. Ефремов, А. С. Насыйбуллин, вахта машинасын йөртүчеләр А. И. Ефремов, Н.Я. Ростворов, тепловоз машинистлары В. А.Логинов, А. Н. Ткаченко һәм башкалар.

Карьерда эшләүчеләргә мохтаҗлык юк. Эшчеләр фатирлар белән дә тәэмин ителгән. Эшчеләр өчен өч торак йорт төзелгән, алар газүткәргечкә тоташтырылган, эшчеләр хезмәт урыннарына махсус автобуста йөриләр.

Хәзерге вакытта коллективның бар тырышлыгы еллык планнарны үтәүгә юнәлдерелгән.

**Р. СӘЙФЕЛМӨЛЕКОВА.**



Озак еллар терлекче булып эшләгәннән соң мөдир итеп куйдылар Григорий Петрович Матвеевны. Хәзер менә 3 еллап инде ул «Мамык» совхозының Сосновка товарлыклы-сәтчелек фермасына җитәкчелек итә. Кырыс холыклы, принципиаль Григорий Петрович коллективны бердәм хезмәткә, маллардан продукция алуны арттыруга тупларга тырыша. Хәзер терлекчелектә иң җитди, җаваплы чор—кышлату чоры башланды. Сосновка фермасында да ул кытыршылыкларсыз гына бармый. Әмма ни генә булмасын, вакытлы кыенлыкларны җиңеп, елны әйбәт күрсәткечләр белән төгәлләүне максат итә Г. П. Матвеев һәм коллективны да шуңа әйдәргә тырыша.

Рәсемдә: ферма мөдире Г. П. Матвеев.

## Газета чыгышыннан соң

**«Сессия үтте— икенче көнне су бетте».**

Газетабызның 1991 елның 12 сентябрьдәге 109 нчы санында әнә шул баш астында мәкалә урнаштырылган иде. Анда Нефтьчеләр урамында яшәүчеләр су юклыктан зарланганнар иде. «Дөрес, быел 1 май һәм 9 Май бәйрәмнәре көннәрендә, район Советы сессиясенә кадәр 1 сентябрьдән 6 сентябрьгә кадәр су биреп алдылар, икенче көнне ул да бетте. Су бирүнең хикмәтен соңыннан аңладык: сессиядә су мәсьәләсе каралган булган икән», дигән юллар бар иде мәкаләдә.

Әлеге язма тикшереп җавап бирү өчен халык депутатларының Норлат шәһәр Советы рәисе М. Фәррәховка җибәрелде. Ул редакциягә түбәндәге җавапны җибәргән:

«Дуслык» газетасында басылган «Сессия үтте— икенче көнне су бетте» дигән мәкаләдә язылганнарга җавап итеп шуны җиткерәм, хәзерге вакытта Нефтьчеләр урамы буенча суүткәргеч алмаштырылды, яктырткычлар ремонтланды.

**Норлат шәһәр Советы рәисе М. Фәррәхов».**

## Яңа сорауга иске җавап

Редакциягә Норлат халкыннан килгән хатларның күбесеннән талоннарга ризык таба алмау турында укыйбыз. Билгеле, андый хатлар райпо җитәкчеләренә юллана. Редакциянең райпо идарәсе рәисе Һ. Х. Садыйковка җибәрелгән 1228 номерлы хатында да шушы ук мәсьәлә күтәрелгән иде. Ләкин яңа сорауга һаман да берүк иске җавап килде. Сез дә таныш булыгыз хөрмәтле укучылар аның белән:

«ТССР Дәүләт планы карары нигезендә райпо 3,6 мең кешегә хезмәт күрсәтә, шуның 2 мең 600е шикәр заводы поселогына туры килә, 1 мең кешегә Красноармейск урамындагы 22 нче кибет хезмәт күрсәтә. Шәһәрнең башка халкы талоннарына азык-төлекне «Норлатнефть» НГДУы, тимер юл, урман промышленносте хуҗалыгы ОРСлары кибетләреннән алалар.

**Райпо идарәсе рәисе Һ. Садыйков».**

**Бу җавапка шуны өстисе килә. Бу хакта халык яхшы белә, хәлне төзәтү өчен нәрсә эшләнергә тиешлеген ишетәсе килә кешеләрнең. Халык талон тотып шәһәрнең бер башыннан икенчесенә чабып йөрүдән гарык булган бит. Кондитер әйберләрен ничә айлар буена күргәннәре юк, башка ризыклар да сирәк була. Шәһәр үзәгендәге берәр кибеттә, мәсәлән, гастрономия яки «Чулпан» кибетендә (аларда сатуда ризык юк диярлек) шул ук ОРСларның берәр кибете әйберләрен сатуны оештыру читен эш булыр идеме икән?! Халыкның соравы, үтенече әнә шул бит.**

Әстәгъфирулла

## „Бозлы бармаклар минем киемемне өзгәләде"

**Күренекле археолог, Швейцариянең хөрмәтле хатын-кыз галимәсе, профессор Рената Цапауль, миңа инклар юлбашчысының 500 еллык мумиясе һөҗүм итте һәм көчләде, дип раслый һәм аңардан бала табарга җыенуын әйтә.**

Профессор Рената Цапауль акылдан язмаган. Үзен психиатрлар һәм гинекологлар каравын, хәлне полиция тикшерүен ул үзе таләп итте.

—Нәрсә дип әйтергә дә белмим, —диде матбугат вәкилләренә Лима гинекологы доктор Мануэль Мендес.—Мин Цапауль ханымны шушы вакыйгадан соң бер сәгать үзгач тикшердем һәм аның чыннан да көчләнгән булуы хакында миндә дәлилләр бар. Мумиядә дә җенси якынлык кылу эзләре сакланган.

37 яшьлек профессор хатын Рената Цапауль журналистларга бу коточкыч хәлнең Цузцо (Перу) тирәсендәге инклар юлбашчысы каберен ачкач булуын әйтте.

—Безнең археологик экспедиция каберлектән ярты чакырымнар тирәсе ераклыкта урнашты. Табылдыгымны күрсәтү өчен мин коллегаларымны чакырырга уйладым. Берничә адым атладыммы-юкмы икән, кемдер миңа арттан һөҗүм итте. Башта миңа гүр салкыны бөркелде, аннары черегән ис тойдым. Башым әйләнем китте һәм мин егылдым. Кемнеңдер өстемдәге киемнәремне йолкуын тойдым.

Аңыма килгәч, үземнең шыр ялангач җирдә ятуымны, ә өстемдә ир кешенең мумияләнгән калдыкларын күрдем. Котым очудан кулым-аягым хәрәкәтләнмәде. Акылдан шашам дип уйладым. Киемнәрем теткәләнеп беткән иде. Үземне көчләгәннәрен тойдым. Өстемнән мумияне төртеп төшердем дә йөгерә башладым. Артымда мышнау, шаркылдап көлү, шау-шу, сөякләр шалтыравын ишеттем. Бу хәл 15 минутлар дәвам итте, ләкин шул чирек сәгать эчендә минем чәчләрем агарды.

**(Чит ил матбугаты материаллары буенча).**

# Тормышыбыз иминлеге өчен

Районда хәл борчулы булып кала бирә. 1991 елның 9 аенда 238 җинаять эше теркәлде. Бу үткән елның шул вакыты белән чагыштырганда 55 кә артык. Аларның 163 очрагы уголовный җинаять. (1990 елда— 111 иде). Аларның 1се үтерү, икесе авыр тән җәрәхәтләре ясау, 5се көчләү яки көчләргә тырышу кебек авыр җинаятьләр.

БХСС линиясе буенча да былтыргы 28 урынына бүгенге көнгә 31 җинаять очрагы теркәлде. Шулай ук 6 мотоцикл, машина урлау, 4 юлда бәрелеп үлү очрагы булды. 9 айга 154 кешегә җинаять эше кузгатылды. Аларның 28е элек тә хөкем ителгәннәр. 51 җинаять исерек хәлдә, 13 җинаять 18 яше тулмаганнар тарафыннан эшләнелгән.

Икенче иң киң таралган җинаятьләрдән хулиганлык кылу тора. Аларның бөтенесе диярлек исерек хәлдә эшләнелгән. 9 айда гына да 37 шундый факт теркәлде.

Шулай ук төрле закон бозу очраклары буенча административ җавапка тартылучылар да шактый күбәйде. Вак хулиганлык кылу очрагы районда 885 кә җитте.

Шулай ук җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөргән һәм аракы эчкән өчен милициягә 776 кеше китерелде. Аларның өчесенә җинаять эше кузгатылды, калганнары административ җавапка тартылдылар.

Әйтеп кителгәннәрдән күренгәнчә, хөкем ителүчеләр елдан-ел арта бара, ә закон бозулар, җинаять кылулар кимеми. Моның сәбәпләре дә юк түгел. Мәсәлән, суд практикасы кешелекләнә баруы нәтиҗәсендә колонияләргә хөкем ителүчеләрнең саны күпкә кимеде. Аннан чыккач та аларга эшкә урнашу, хәзерге вакытта бигрәк тә, бик кыен. Күп предприятиеләрдә, төрле сәбәпләр табып, андыйлардан йөз чөерәләр. Нәтиҗәдә кеше кире җинаять юлына басарга мәҗбүр була.

Соңгы вакытта шулай ук беркайда да эшләмәүчеләрнең саны арта бара. Бүгенге көнгә районда 46 кешенең беркайда да эшләмәве ачыкланды һәм аларга официаль кисәтү ясалды.

Безне бигрәк тә балигъ булмаганнар тарафыннан җинаять эшләү, тәртип бозу очраклары нык борчый. Үсмерләр арасында күмәкләшеп сугышу очракларын булдырмас өчен генә дә безгә күпме көч, вакыт сарыф итәргә туры килә. Монда ата-аналарга да үз балаларының буш вакытларын, кичләрен ничек, кайда үткәрүләре, аларның җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тотышлары белән кызыксынырга киңәш бирәсе килә. Бу милиция сотрудникларының үзләренең турыдан-туры бурычлары— җинаятьчелек белән көрәш, җәмәгать тәртибен саклау һәм закон бозуларга каршы профилактик чаралар үткәрү белән күбрәк шөгыльләнергә мөмкинлек бирер иде. Шулай ук монда бөтен җәмәгатьчелек тотынып, үсмерләрнең ялын оештыру, аларны җәмгыятькә файдалы эшкә тарту һәм кешелеклелек, инсафлылык кебек аңлатмаларны төшендерү зарур.

Бу язмада тагын бер җитди проблема булган акча, дәүләт һәм шәхси милек урлану очраклары турында әйтми мөмкин түгел. Моңа бигрәк тә алар саклана торган объектларның яхшы ныгытылмавы, начар бикләнгән булуы, ә өйләрнең ишекләрендә ныклы, ышанычлы бикләрнең булмавы да юл ача. Биредә инде билгеле булган кайбер саклык чараларын кабатлап үтү кирәктер. Иң беренчесе—районның эчке эшләр бүлегенә мөрәҗәгать итеп, саклык сигнализациясе урнаштыру. Сезнең игътибарны шулай ук урланган әйберләрне сатып алучыларны ачыклап, милициягә хәбәр итү зарурилыгына юнәлдерәбез. Бу уңайдан автомашиналар яисә машина салонында калган радиоалгычлар, магнитофоннар һәм башка әйберләрне урлау очраклары ешаюны да истән чыгарырга ярамый.

Аларны ышанычлы саклау өчен шәһәрдә түләүле саклау урыннары, гаражлар җитми. Бу шулай ук кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәлә.

Соңгы вакытта районда ДНД эше бөтенләй сүлпәнләнде. Алар җәмәгать тәртибен саклауда бөтенләй диярлек катнашмый башладылар. Предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәбез: ДНД эшен яңадан торгызуга конкрет чаралар, аларны матди кызыксындыру чаралары күрелергә тиеш.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: милиция үзе генә **хезмәт коллективлары һәм киң җәмәгатьчелектән башка җәмәгать тәртибен саклауны тулысы белән тәэмин итә алмый. Шуңа күрә без сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Бу уңайдан сездән тәкъдимнәрегезне,** күрсәтеп кителгән фактлар буенча фикерегезне беләсе килә.

**Д. МӨХЕТДИНОВ,**
җәмәгать куркынычсызлыгы өлкән инспекторы, милиция өлкән лейтенанты.

